**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2023 елның 30 ноябре

Халык алдында тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы - Совет рәисе инициативасы белән үткәрелде, 2023елның 23 октябрендәге 102-РС номерлы карар белән билгеләнде.

Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2023 елның 23 октябрендәге 102-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023 елның 25 октябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2023 елның 25 октябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2023 елның 25 октябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 30 октябрендәге 10412/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында 2023 елның 30 октябрендәге 10412/исх номерлы хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023 елның 31 октябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2023 елның 1 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2023 елның 31 октябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе рәисе урынбасары- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Прокофьева Любовь Ивановна - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның 29 ноябрендә Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 7 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулары нәтиҗәләре:

1.Халык тыңлауларын узган дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Александр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын, 2023 елның 29 ноябрендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге нәтиҗәдән өземтәләр бирергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ____________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________ Прокофьева Л.И.